Газета 2005 елда чыга башлады

# Яңарыш

08
2015

Теләче районы Шәтке урта гомуми белем бирү мәктәбенең айлык газетасы

# Иҗади эзләнүләр юлыннан

Шәтке урта мәктәбе педагогик коллективы “Заманча технологияләр куллану юлы белән укыту һәм тәрбиянең сыйфатын күтәрү” проблемасы өстендә эшләде.

Узган уку елында педагогик коллектив алдына түбәндәге бурычлар куелган иде:

1. Укыту-тәрбиянең сыйфатын күтәрү һәм яңа технологияләр кулланып эшләү.
2. “Татарстан балалары” республика программасын гамәлгә ашыру.
3. “Мәгариф һәм сәламәтлек” дигән республика программасын гамәлгә ашыра барып, укучыларның сәламәтлеген һәм физик үсешен ныгыту.

Шәтке урта мәктәбенең 20 кешелек укытучылар коллективы шушы бурычларны гамәлгә ашыру өстендә максатчан эш алып бардылар. Һәр фәнне үз белгечлеге буенча белем алган мөгаллим укытты. Укытучыларыбызның күбесе үз эшләренең чын осталары:
2 югары категорияле (10,5%) , 13 укытучы – 1 нче квалификацион категориягә ия (78,6 %), 1 укытучы 2 нче квалификацион категорияле (5,25%). Алар балаларның танып-белү активлыгын үстерү, һәр дәресне иҗат, шатлык дәресе итү өчен тырышалар.



Уку елы дәвамында мәктәптә 8 педагогик киңәшмә үтте. “Яңа стандартларга күчеп укыту”, «Сәләтле балалар белән эшләү үзенчәлекләре”, “Табигать фәннәрен укытуда яңа технологияләр куллану”, “Метапредмет биремнәр: башлангыч сыйныфларда тәҗрибә уртаклашу”, “Бердәм дәүләт имтиханнары турында 2014-2015 уку елында үзгәрешләр” дигән темаларга докладлар укып өйрәнелде. Айга ике тапкыр директор янында киңәшмәләр үтте. Аларда укыту-тәрбия процессының төп мәсьәләләре тикшерелде, кимчелекләрне бетерү юллары күрсәтелде, сәләтле балалар белән эшне оештыруның яңа формалары билгеләнде.


Сәләтле балалар белән сәгатьләп индивидуаль шөгыльләнү уңай нәтиҗәләр бирде.

11 сыйныф укучысы Габдриев Ирек районда беренчеләрдән булып рус теле, математика, физика фәннәреннән 76 балл җыеп, республика һәм Россиянең алтын медален алуга ирешә. Кадыйрова Зөһрә Россия медаленә лаек булды.



Укучыларның Бөтенроссия олимпиадасының муниципаль турында призлы урыннарны яулаучы укучылар:
11 сыйныф укучылары - Мухаметзянов Рамазан информатика, ТИН фәннәреннән, Габдриев Ирек география, геологиядән , Галимуллина Алинә биология һәм татар әдәбиятыннан , 10 сыйныф укучысы Галиева Алинә биология фәненнән, 9 нчы сыйныф укучысы Габделхаев Рәсим география белән геологиядән, 7 сыйныф укучысы Мавлин Эмиль рус теленнән 1 урыннарны яуладылар.
Музафарова Айсылу физикадан , 7 сыйныф укучысы Абзалилов Иршат физкультура фәненнән 2 урын алуга ирештеләр.
Габдриев Ирек һәм Габделхаев Рәсим геология олимпиаданың республика турында да яхшы гына катнашып, уңай нәтиҗәләргә ирештеләр.

Быелгы уку елында мәктәп эчендә ачык дәресләр һәм семинарлар мультимедиа, интерактив такта, Сингапур методикаларын кулланып үткәрелде.



Мәсәлән, декабрь аенда ” Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә төрле инновацион технологияләр кулланып, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү” дигән темага татар теле һәм әдәбияты укытучыларының район семинары узды. Анда Габделхаева Р.Х. һәм Заляева Г.М.лар үзләренең эш тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, ачык дәресләр, Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган чара күрсәттеләр. Март аенда шундый ук семинар “Дистанционное обучение и новые формы дистанционной поддержки учащихся и учителей” дигән темага информатика фәненнән үтте. Әлеге семинарларда укытучылар үзләрен борчыган проблемалар турында түгәрәк өстәл артында фикер алыштылар.

Узган уку елында мәктәптә башлангыч сыйныфлар, химия, Габдулла Тукай туган көненә багышлап татар теле атналыклары, оборона-масса айлыгы үткәрелде. Атналыкларда укучылар бик теләп катнаштылар, үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар таптылар. Тукай атналыгы барышында укучылар өчен үзләре иҗат иткән шигырьләр, рәсемнәр, иң чиста дәфтәр, Тукай шигырьләрен сәнгатьле сөйләү конкурслары үткәрелде.



2014-2015 уку елында укытучыларыбыз район, республика күләмендә үткәрелгән конкурсларда, эксперименталь-тәҗрибә эшләрендә, фәнни-гамәли конференцияләрдә актив катнаштылар.

Башлангыч сыйныф укытучысы Равия Гимадиева “Наш лучший учитель” конкурсында җиңеп, Грантка ия булды. Химия укытучысы Габдуллина Р.Г. КНИТУ үткәргән «Лучшая методическая разработка урока химии -2014» республика конкурсында катнашып, лауреат Дипломына ия булды. Биология укытучысы Шайхиева И.М. Бөтенроссия мәктәп яны тәҗрибә участогы күргәзмәсендә катнашып, Диплом белән бүләкләнде.

Хафизова Ф.А. һәм Идрисова М.С. математика укытучыларының 9нчы Бөтенроссия олимпиадасында катнашып, Дипломга лаек булдылар.

*Ризида Габдуллина, укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары*

# Тәрбия – мөһим эш

Быелгы уку елы Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган чаралар белән башланып китте. Без, бөтен көчебезне куеп, бу елны файдалы һәм истә калдырырлык итеп үткәрергә тырыштык.

Уку елы дәвамында безнең укучылар район һәм мәктәп күләмендә үткәрелгән чараларда актив катнашып килделәр.

Быел, югарыда әйтелгәнчә, Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган чаралар һәм конкурслар күп булды. Мәсәлән, ноябрь аенда үткәрелгән “Җиңүгә илткән юллар” фестивалендә катнашып, безнең Шәтке мәктәбе 3 у дәрәҗә лауреат исеменә лаек булды. “Подвигу народа жить в веках” исеме астында үткәрелгән иҗади конкурста Кадыйрова Фәйрүзә, Заляева Диана һәм Заляева Лиана Мактау Грамотасы белән бүләкләнделәр. 8 нче сыйныф укучысы Кыямов Риназ ”Родные лица победы” баннер яклау конкурсында 3 урынга һәм республикакүләм яңа инновацион технологияләр кулланып,





“Мир сегодня и завтра – 2015” иҗади эше өчен сертификатка ия булды. Мечты детства: “Юные мастера и подмастерья” конкурсында Сонгатова Тансылу(кул эшләре), Галияхметова Илгизә (рәсем) катнашып, грамотага ия булдылар. “Детская организация – в делах и лицах” фотоконкурсында Музафарова Айсылу 2 урын яулады. “Памяти павших будем достойны” дигән темага авыл һәйкәл-обелиск тарихлары язылып, папкалар ясалды.

Шулай ук ветеран һәм тыл ветераннары, сугыш чоры балалары белән төрле чаралар үткәрелде: “Медаль тапшыру” тантанасы, “Батырлар даны мәңгелек” ( әдәби-кичә), “Онытырга мөмкин түгел” сугыш чоры балалары белән очрашу кичәсе.

Укучыларыбыз сәнгать һәм моңга гашыйк кешеләр. Мәсәлән, сәнгатьле сөйләү буенча “У войны не детское лицо” конкурсында 1 һәм 2 нче урын алган укучыларыбыз бар: Мухаметзянов Рамазан (11 сыйныф), Кадыйрова Фәйрүзә (10 класс), Саттаров Адель (4 класс), Мавлина Зәлия (8 сыйныф). “Туган телем – серле тел” республикакүләм конкурсында Сонгатова Тансылу (6 нчы сыйныф) 2 урын, Ибраева Зөхрә (4 нче сыйныф) 3 урынга лаек булып, Диплом белән бүләкләнделәр.

Районда Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап, “Салют Победы” фестивалендә Мухаметханов Айсаф, баянда уйнап, “үзенчәлекле жанр” номинациясендә 1 нче урынга лаек булды. Яшел Үзән шәһәрендә үткән “Феерия Аккордеона” фестивалендә катнашып, Дипломга, Габдулла Тукайның тууына129 ел тулуга багышлап, Арчада үткәрелгән 10 нчы Республика “Арча ягы-данлы Тукай ягы” конкурсында 3 дәрәҗә лауреат, “Җиңүгә илткән юллар” фестивалендә “Халык уен кораллары” номинациясе буенча 1 урынны алуга иреште. “Җиңүгә илткән юллар” фестивалендә хореография номинациясе буенча “Тамчыкай” бию төркеме 3 урын яулады.

“Җиңү җыры” иҗади конкурсында Кадыйрова Фәйрүзә үзе язган шигырьләр белән катнашып, сертификатка лаек булды.

Февраль аенда үткәрелгән "Созвездие Йолдызлык - 2015» фестиваленең район авыллары арасында зона ярышлары булып үтте. Бу ярышта безнең мәктәбебездән барлыгы 14 укучы катанашты. Ярыш бик киеренке булды, барлык укучылар да яхшы әзерлек белән килгәннәр. Җюри нәтиҗәләре буенча район турында катнашу өчен безнең укучыларыбызны да алдылар:

- конферанслар - Мухаметзянов Рамазан, Кадыйрова Фәйрүзә;
- “Тамчыкай” бию төркеменең “Морячка” биюе.

“Татарстан республикасы символикасы” дигән темага язылган тарихи эзләнү материалы белән Сонгатова Тансылу 1 урынга лаек булды.

Укучылар рәсем ясау белән дә шөгыльләнәләр. Коррупциягә каршы “Надо жить честно!” исеме астында үткәрелгән республика рәсемнәр конкурсында 4 нче сыйныф укучысы Гимадиев Булат катнашып, 1 нче урын яулады.

XIII регионара Каюм Насыйри укуларында 8 нче сыйныф укучысы Мавлина Зәлия экология фәне буенча катнашып, Мактау кәгазе белән бүләкләнде.

2015 ел - Әдәбият елы буларак билгеләп үтелә һәм шушы уңайдан Шәтке авылы мәдәният йортында "Сагынып кайтам сиңа, Шәткемә!" дип исемләнгән язучылар белән очрашу кичәсе үткәрелде. Якташ язучыларыбыздан Нурислам Хәсәнов, Сәйдә Зыялы, Нурулла Гаптуллин һәм Зөлфирә Котдусовна килгән иде. Кичәдә язучыларыбыз иҗат юллары белән танышытырдылар, киләчәк буынга теләкләрен һәм рәхмәтләрен белдерделәр. Бәйрәмдә укучыларыбыз язучыларның шигырьләрен сөйләде, кичә концерт номерлары белән үрелеп барды.

Спорт та мәктәбебездә киң колач алган. Хоккей буенча шушы уку елында “хоккей” түгәрәгенә йөргән балалар белән төрле ярышларда катнашылды һәм нәтиҗәләре дә уңай булды. Шулай ук волейбол кызлар командасы беренчелекне бирмәделәр.

9 май - Бөек Җиңү көне. Бу көн безнең илебез гаскәрләре илебезне азат иткән көн. Шушы матур бәйрәмне каршылау уңаеннан мәктәбебез укучылары үзләренең чыгышларын әзерләп, сугыш ачысын татыган барлык авылдашларыбызны тәбрикләп





киттеләр һәм “Бессмертный полк” акциясендә катнаштылар. Мәктәбебез укучылары ярдәмчесез калган картларның, ялгызларның, сугыш, тыл, хезмәт ветераннарының өйләренә бардылар, аларның хәлләрен белеп, ярдәм иттеләр.

Һәр классның, һәр отрядның үзләренә билгеләп куелган өлкәннәре, ялгыз булган кешеләре, ветераннары бар. Алар график нигезендә эшне алып баралар. Билгеле инде, аларның һәркайсына социаль ярдәм бүлегеннән, карауччылар да билгеләп куелган, ләкин шулай булуга карамастан, укучылар бу кешеләргә теләп йөриләр.



19 Май – Пионериянең туган көненә карата “Кече Сабантуй” үткәрелде. Ул оешкан төстә, күңел ачу һәм спорт ярышлары белән берлектә аралаштырып алып барылды, ел буе иң актив булган укучылар бүләкләнде. Укучылар пионер һәм комсомолларның үткән тарихы турында сөйләделәр , дружинаның еллык отчеты тыңланды, 4 сыйныф укучылары варислар сафына кабул ителде. Пионер җырлары җырланды , төрле уеннар уйналды.

Сәламәтлек турында кайгырту – тәрбия эшенең гаять әһәмиятле өлеше. Баланың шат күңелле, тормыш сөючән булуы аның рухи тормышына, дөньяга





карашына көчле йогынты ясый, акыл үсешенә уңай тәэсир итә, белемнең ныклыгына, үз көченә ышаныч тудыра. Баланың физик үсеше һәм сәламәтлеге аны шәхес итеп формлаштыруда нигез булып тора. Менә шуны истә тотып, без быел “Сәламәтлек көне”, “Наркомания – бәла билгесе” – диспут, әңгәмәләр һәм психолог белән очрашулар оештырдык, анкеталар үткәрдек.

Ата – аналар белән эшләү дә мәктәптә яхшы оештырылган. Класс җитәкчеләре әти-әниләр белән даими элемтәдә торалар, өйләренә барып укучыларның дәрес әзерләүләре белән кызыксыналар, әти-әниләр белән индивидуаль консультацияләр үткәрәләр. Әти-әниләр балаларының дәресләренә килеп утыралар, класстан тыш чараларда катнашалар. Һәр чирек саен әти-әниләр җыелышлары үткәрелә. Әлеге җыелышлар “Тәртип бусагадан башлана”. “Әти,әни һәм мин – сәламәт гаилә”, “Бәхет башы -тәүфыйк”, “Эшләгән эшеңә җавап бирә бел!” Һ.б. темалар буенча үтте.



Укучылар мәктәпнең укыту-тәҗрибә участогында яшелчә, җиләк-җимеш үстерүдә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Алар эшчәнлеге нәтиҗәсендә ел әйләнәсендә ашханәдә үзләре житештергән яшелчәләрдән кайнар ризык әзерләнә. Укучылар, шулай ук, Шәтке күмәк хуҗалыгына да язгы, көзге кыр эшләрендә, ындыр табагында, терлекчелек тармагында булышалар.

Шулай итеп, мәктәптә һәр укытучы белем һәм тәрбия бирүне нәтиҗәле оештырганда, бу эшкә ата-аналарны, киң җәмәгатьчелекне җәлеп иткәндә , укыту-тәрбиядә яңа алымнар, яңа эш формалары кулланганда гына без тиешле нәтиҗәгә ирешә алабыз.

*Илнар Музафаров, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары*

# Башлангыч сыйныфларда

Башлангыч класс укытучыларының методик берләшмәсе “Яңа методик технологияләр кулланып, традицион укыту формаларын камилләштерү” темасы өстендә эш алып барды. Укыту процессында яңа инновацион технологияләр кулланып, укучыларны бердәм дәүләт имтиханнарын тапшыру дәрәҗәсенә җиткерү бурычын төгәл үтәделәр.





Укучылар район олимпиадаларында һәм класстан тыш чараларда актив катнашып, үзләренең иҗади сәләтләрен, белем дәрәҗәләрен үстерү өлкәсендә эшләделәр. Район олимпиадасында Закирова Чулпан (4 сыйныф) рус теле фәненнән 2 нче урынны, Ибраева Зөһрә (4 сыйныф) математикадан 3 нче урыннарны яуладылар. Башлангыч сыйныф методик берләшмәсе укытучылары сәләтле балалар белән эшләүне ел дәвамында алып бардылар.



Үзләренең белем дәрәҗәләрен үстерү өлкәсендә укучылар төрле фәннәрдән үткәрелгән мониторингларда, конкурсларда, уеннарда катнаштылар: “Русский медвежонок”, “Кириллица”, “Кенгуру”, “Кит”, “Зирәк тиен”, “Татар Теле Инфо”. “Антикоррупция”гә каршы үткәрелгән рәсем конкурсында (1 урын), “IT – чемпион” номинациясендә “Иң актив укучы” җиңүчесе, “Туган телем-серле тел” сәнгатьле сөйләм конкурсында, “Яшел математика” турнирында актив катнаштылар.

Методик берләшмә укытучылары ачык дәресләр, мастер – класслар үткәрделәр, үзләренең мәкалә, очеркларын брошюра өчен тәкъдим иттеләр: “Башлангыч сыйныфта экологик тәрбия” (Хусаинова М.Г.), “Без табигать балалары” (Шайхутдинова Р.В.), “Дәресләрдә табигатькә мәхәббәт тәрбияләү” (Давлетшина Р.Х.), “Дәрестән тыш чараларда укучыларга экологик белем һәм тәрбия бирү” (Гимадиева Р.С.).

Бөтенроссия күләмендә үткәрелгән “Ачык дәрес” конкурсында Шайхутдинова Роза лауреат дипломына лаек булды, Давлетшина Рәзинә сертификат белән бүләкләнде, Хусаинова Мөнирә “Белем.ру” сайтында “Иң яхшы методик дәрес эшкәртмәсе” белән катнашып, сертификат алу дәрәҗәсенә иреште. Гимадиева Равия “Иң яхшы укытучы” Грантына ия булды.

Укыту-тәрбия процессында яңа технологияләр һәм алымнар кулланып, башлангыч сыйныф методик җитәкчеләре укучыларның белем дәрәҗәләрен үстерүгә бик күп көч куйдылар.

Сыйфат дәрәҗәләре: 78%

“5” – 22%

“4” һәм “5” – 57%

*Равия Гимадиева, башлангыч сыйныфлар методик берләшмәсе җитәкчесе*

# Күңелле җәйге яллар

Шәтке урта мәктәбендә “Шатлык” мәктәп яны лагере эше мавыктыргыч, тәрбияви яктан югары дәрәҗәдә һәм бик күңелле итеп оештырылды. Ул 2 июньнән балаларны кабул итте. 18 көндә җиде яшьтән алып унике яшькә кадәрге 30 бала ял итте һәм үз сәламәтлеген ныгытты. Балалар бирегә бик теләп йөрделәр. Чөнки аларның ялы үзенчәлекле, эчтәлекле һәм күңелле үтте.



Иртәләребез зарядка белән башланып китте, ачык һавада төрледән-төрле уеннар оештырылды, табигать кочагына, авылыбыз урамнарына экскурсияләргә бардык. Иң матур йортлар, иң чиста урам, яшел урам билгеләнде**.** Шәтке авылы янындагы коры елгаларга, Теләченең “Туган якны өйрәнү” музеена экскурсияләр үткәрелде. Укучыларыбыз һәртөрле башваткычларны бик теләп чиштеләр, шахмат турнирында, җиңел атлетика, бадминтон, волейбол һәм футбол буенча спорт ярышларында катнаштылар.



Бу ял хезмәт белән үрелеп барды. Чишмә территориясе җыештырылды, балалар көче белән дару үләннәре: кычыткан, сукыр кычыткан, әрем җыелды. Лагерьның тәрбия эше төрле вакыйгалар, очрашулар, күңелле экскурсияләр, тематик кичәләр белән баетылган иде. Без, тәрбиячеләр Роза Шайхутдинова, Мөнирә Хусайнова, Фәридә Хафизова, Сөмбел Мозафарова, балаларның лагерьдагы һәр көне күңелле, истәлекле, тәрбияви булсын дип, бик күп чаралар үткәрергә тырыштык. Россия көненә презентация эчтәлекле булды.. “Шәтке авылы тарихы” дигән темага чыгыш ясалды. Балаларның су буеннан бер дә кайтасылары килми, сагынып көткән җәй бит ул... “Иң оста һәм иң күп балык тотучы” конкурсы үткәрелде.. “Герой пионерлар”, “Ленинград блокадасы” темаларына тәрбия сәгатьләре үткәрелде.



Ә Хәтер һәм кайгы көнендә Бөек Ватан сугышында һәлак булган якташлары һәйкәленә чәчәкләр куйдылар.

Азаккы көннәрнең берсендә кече сабантуй үткәрдек. Бөтен балалар да уеннарда катнаштылар һәм истәлекле бүләкләр алдылар Лагерьда үткәрелгән барлык чаралар ватан-пәрвәрлек, татулык, үз төбәгең белән горурлану хисләрен арттырды,дип уйлыйм. Балалар да, әти-әниләр дә канәгать калдылар. Малайлар һәм кызлар кояшта кызындылар, ял иттеләр, тәмле итеп ашадылар һәм көннәрен файдалы итеп үткәрдедәр.

*Мөнирә Хусайнова,башлангыч сыйныфлар укытучысы.*

# Мәк чәчәге



**Габделхәева Рәзифә Хәкимҗан кызы.**
*I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Ә .Еникиның “Мәк чәчәге” әсәре буенча дәрес фрагменты**

***Дәреснең максаты:*** коммуникатив һәм танып белү универсаль уку күнекмәләрен булдыру; зур корбаннар бәрабәренә яуланган, көл һәм каннан үсеп чыккан Бөек Җиңү һәм аның каһарманнарын без онытырга тиеш түгел.

***Метапредмет белемнәр:*** символ, текст белән эш.

**Сингапурча укыту методикасы буенча кулланылган структуралар:** Эй АР ГАЙД, СИНГЛ РАУНД РОБИН, ТАЙМД ПЭА ШЭА, МИКС ПЭА ШЭА, ЗУМ ИН, ФИНК - РАЙТ – РАУНД- РОБИН.

**Укытучы.** Исәнмесез, укучылар!
Хәерле көннәр сезгә!

**Укучылар.** Исәнмесез! Хәерле көн
Телибез без дә Сезгә!

Укытучы. Укучылар, безнең бүгенге дәресебезгә кунаклар да килгән. Әйдәгез алар белән дә исәнләшеп алыйк әле.

Укучылар. Исәнмесез! Хәерле көннәр сезгә!

Укытучы. Ә хәзер бер-беребезгә карап елмаеп сәлам бирик һәм дәресебезне башлап җибәрик. Барыгызга да уңышлар телим!

Укучылар, экранга игътибар итегез әле. *(Укучыларга слайдта чәчәкләр күрсәтелә ).* Сезнең каршыда чәчәкләр, аларга карагач, сезгә рәхәтме?

Укучы. Әйе, рәхәт, чәчәкләрнең нәфис төсләре күзләрне иркәли.

Укытучы. Ә чәчәкләр нәрсә символы соң? Алар кайчан һәм кемнәргә бүләк ителә?

Әле генә әйткән сорауларга җавапларыгызны, ягъни үз фикерләрегезне алдыгыздагы битләргә языгыз. *(балалар үз фикерләрен язалар).*

Укучылар. **(СИНГЛ РАУНД РОБИН структурасы буенча җавап бирәләр: команданың 4 кешесе дә чиратлап җавап бирә).** Чәчәкләр - ихтирам, хөрмәт билгесе. Аларны яраткан кешеләргә бирәләр, чөнки чәчәкләр матурлык тудыралар. Аларны әниләргә, апаларга, әбиләргә туган көннәренә, 8 март бәйрәмнәрендә бирәләр. Шулай ук егетләр яраткан кызларына да бүләк итә. Концертларда артистларга бирәләр.

Укытучы. Әйе, бик дөрес әйтәсез. Инде әле генә язган фикерләрегез астына сызып куегыз. Ә хәзер яңадан игътибарны экранга юнәлтик. Без сезнең белән Юрий Антонов башкаруында «Маки, маки, красные маки» җыры белән видеоролик карап үтәрбез. *(Видеоролик күрсәтелә).*

Укытучы. Хәзер алдагы сорауга сызык астына кабат җавап язабыз. Ике өлешне чагыштырабыз. Аерма булдымы? Димәк, чәчәкләр нәрсә символы да?

Укучы. Чәчәкләр ярату, хөрмәт символы гына түгел, ә хәтер символы да икән әле. Без әлеге видеороликтан сугыш вакытында һәлак булганнарны хәтеребезгә төшердек. Шулай ук чәчәкләрне алар истәлегенә дә куялар икән бит.

Укытучы. Әйе, укучылар, бик дөрес әйттегез. Димәк, безнең бүгенге дәресебез нәрсә турында булыр?

Укучы. Без бүгенге дәресебездә хәтер турында сөйләшербез.

Укытучы. Ә сезнеңчә, өй эшеннән чыгып, без нинди бәйләнешне ачарга тиеш соң?

Укучы. Без бу дәрестә мәк чәчәге белән хәтер арасындагы бәйләнешне ачарга тиеш.

**2 нче өлеш *(Балалар хәтергә үз билгеләмәләрен бирәләр. Аннан соң аңлатмалы сүзлектәге билгеләмә белән чагыштыралар).***

Укытучы. Ә нәрсә соң ул хәтер? (*Укучылар үзләренең фикерләрен әйтәләр).*

Укучы. Нәрсәне дә булса искә алу, онытмау.

Укытучы. Әйе. Ә менә фәндә хәтер турында ни әйтелә икән соң? Хәзер ике төркемгә бүленеп, беренче төркем татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән, ә икенче төркем миллият сүзлегеннән хәтернең билгеләмәсен карыйк. *(Укучылар сүзлекләрдән карыйлар).*

1 нче төркем. Хәтер – элек булган истәлекләрне, тәэсирләрне, баштан узганнарны аңда саклау сәләте.

2 нче төркем. Хәтер – гарәпчә хатир сүзеннән. Күңелгә ала алу, истә калдыру сәләте.

Укытучы. Ә хәзер табылган нәтиҗәләрне чагыштырып үтик, аларны берләштерсәк ни була?

Укучы. Әйе, бу ике сүзлектән алган белешмәне берләштереп була һәм бу күбрәк тә мәгълүмат бирәчәк. *(укучылар бер- берсенең мәгълүматын дәфтәрләренә өстәп куялар)*

Хәтер- гарәпчә хатир сүзеннән. Күңелгә ала алу, истә калдыру сәләте. Элек булган истәлекләрне, тәэсирләрне, баштан узганнарны аңда саклау сәләте.

Укытучы. Ә ул сезнең үз билгеләмәгез белән туры килдеме?

Укучы. Сүзлекләрдәге билгеләмә белән безнең билгеләмә туры килә, әмма сүзлекләрдә билгеләмә тулырак чагылган .

Укытучы. Ә әдәбиятта хәтергә урын бармы соң?

Укучы. Әйе, бик күп әдәби әсәрләр язучы хәтерендәге вакыйгаларга нигезләнеп языла.

**3нче өлеш (ТАЙМД ПЭА ШЭА структурасы буенча) укучылар парларга бүленәләр һәм кара-каршы партнерлар бер-берсенә нәсернең эчтәлеген сөйлиләр.**

Укытучы. Сез өйдә «Мәк чәчәге» әсәре белән танышырга тиеш идегез. Әйдәгез хәзер каршы парыгызга нәсернең эчтәлеген сөйләп чыгыйк. (*Укучылар каршы парларына нәсернең эчтәлеген сөйлиләр.)*

***4 нче өлеш – теория.***

Укытучы. Укучылар, уйлап карагыз әле, әлеге әсәр Ә. Еникиның нинди кичереш, истәлеге буенча иҗат ителгән әсәре икән? Укучы. Сугыштан соң калган җимерекләкләр турындагы хисләренә нигезләнеп язылган.

Укытучы. Әйе, укучылар, ә «Мәк чәчәге» нинди жанрда язылган соң?

Укучы. “Мәк чәчәге” әсәренең күләме зур түгел, ул лиро-эпик эчтәлектә, нәсер жанрында язылган.

Укытучы. Бик дөрес әйтәсез. Бу нәсердә төп өлешне нәрсә биләп тора соң ?

Укучы. Әлеге нәсердә мәк чәчәге монологы төп өлешне биләп тора.

Укытучы. Ни өчен? Фикерләрегезне дәлилләү өчен, әсәрдән шул урынны табып укып күрсәтегез әле.

Укучы. *(Китаптан шул урынны табып укып күрсәтә 1 укучы.)* «Киң авызлы тирән бомба чокырының төбендә үсеп утырган ялгыз мәк чәчәге чокыр кырыена килеп баскан бер узгынчы солдатка сүз башлый.»

Укытучы. Ә монолог нәрсә ул?

Укучы. Монолог ул - бер персонаж сөйләме. Биредә ул - мәк чәчәге монологы.

Укытучы. Укучылар , ә символ нәрсә ул ? Аңлатмалы сүзлектән тиз генә карап алыйк әле шуны.

Укучы. *(Сүзлектән табып укыйлар).* Символлар - билге дигән сүз, ягъни белдерәсе килгән фикер яки җөмләләрне билге аша күрсәтү.

Укытучы. Без символлар белән тагын кайларда очрашабыз?

Укучы. - Әдәбиятта, юл билгеләрендә, информатикада, төшләрдә.

**5 нче өлеш- карта буенча эш.**

Укытучы. Укучылар, игътибар итик әле: «Мәк чәчәге» нәсерендә төп образ нәрсә? Аңа без нинди бәя бирәбез?

Укучы. Мәк чәчәге. Ул - матур, нәзберек, әз генә җилдән дә таҗлары леперләп тора. Автор әсәрдә аның турында : «Ә хәзер күрәсез: сылу бер чәчәк булып үсеп утырам!», - дип яза.

Укытучы. Шундый матур чәчәк кайсы вакытта үсә соң? Ягъни , ул яшәгән җирлек һәм вакыт?

Укучы. Мәк чәчәге бомба чокырында үсә. Автор аны 1944 елны яза.

Укытучы. Укучылар, һәрбер төркемнең дә өстәлендә сораулар язылган карточкалар ята. Алар номерланган. Димәк, шул номерда утырган кеше каршы күршесенә әлеге сорауны бирә. Ә каршы күршесе әлеге сорауга җавап бирә.

**ТАЙМД ПЭА ШЭА структурасы буенча кара-каршы партнерлар бер-берсе белән эшлиләр.**

1. Ил тарихында 1944 нче ел нәрсәсе белән истә калган ?

*( Җавап бирүче укучы карта ярдәмендә 1944 елда Совет гаскәрләренең торышын күрсәтеп сөйли).*

2. «Мәк чәчәген» язганда автор нинди иҗади югарылыкта була ?

Укучы. Бу вакытта Ә. Еники җитлеккән язучы була. Ә. Еники - Ватан сугышы фронтында: хәрәкәттәге армиянең хуҗалык һәм каравыл частьләрендә рядовой солдат булып хезмәт итә. Шуңа күрә язучы «Мәк чәчәгендә» дә сугыш үткән җирләрнең кызганыч картинасын сурәтләп яза. *( Китаптан укып күрсәтә* 3. Тарихи вакыйгалардан чыгып, «Мәк чәчәге» нинди рухта язылган дип әйтә аласыз?

Укучы. Әлеге әсәр горурлык, киләчәккә өмет рухында язылган. «Минем баш өстемдә еракта, бик еракта нурлы күк…" Бу сүзләр аша тиз булмаса да, җиңүгә ышаныч зур икәнлеген күрәбез.

Укытучы. Әйе, укучылар, «Мин – дөньяның матурлыгыннан туймаган, һаман да аны матур итәргә теләгән ялгыз мәк – сезнең үткән адымыгыз артыннан чәчәкләр үсеп калуын теләр идем,»- дип әйтә ул солдат белән саубуллашканда.

**Ял минуты. МИКС ПЭА ШЭА структурасы буенча ял итеп алалар.**

Укучыларга түбәндәге сораулар тәкъдим ителә:

1. “Мәк чәчәге” әсәрен кем язган? (Ә.Еники).
2. Әсәр нинди жанрда язылган? (Лиро-эпик эчтәлектә, нәсер жанрында).
3. Әсәрдә кайсы сугыш турында сөйләнә? (Бөек Ватан сугышы).
4. Әсәрдә төп өлешне нәрсә алып тора? (Мәк чәчәге монологы).

**6 нчы өлеш (ЗУМ ИН структурасы*)* – мәк чәчәге образын төрле яклап тикшерү.**

Укытучы. Укучылар, ә бу әсәрдә мәк чәчәге символ була аламы? Тагын аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итеп алыйк әле.

Укучы. *(Укучылар аңлатмалы сүзлектән мәк чәчәге турында билгеләмәне табалар).*

Мәк - бу атама рус теленнән алынган, ә рус теленә ул грек теленнән кергән дип уйлыйлар. *(грекча махас- -мәк, русча-мак*Укытучы. Яхшы. Әсәрдә мәк чәчәге кайда үсә соң?

Укучы. Мәк чәчәге бомбадан калган чокыр уртасында үсә **.**

Укытучы. Шулай. Бу әсәрдә төп герой дип нәрсәне атап булыр иде?

Укучы. Төп герой – Мәк чәчәге. Солдатны алдагы юлының бик авыр булырын, әмма бу аерылуның вакытлы икәнлеген искәртә. «Сездән аерылу авыр… әмма бу вакытлы… Сез көнбатышка таба барасыз! Сезне анда канлы сугышлар көтә булыр….»

Укытучы. Әсәрдә ярдәмче геройлар бармы? Булса, алар ни өчен хезмәт итә?

Хәзер алдыгыздагы кәгазь битләренә һәрберегез бер ярдәмче герой турында языгыз һәм соңыннан фикерләрегезне берләштереп, җавап бирерсез.

**ФИНК - РАЙТ – РАУНД- РОБИН структурасы буенча эшләү.**

Укытучы. Һәр командадан да өченче номерлы укучы гомуми җавапны бирә.

Укытучы. Бик дөрес әйтәсез, укучылар. Ә ни өчен автор үзенең төп герое итеп мәк чәчәген сайлады икән, ни өчен роза да түгел, пион да түгел?

Укучы. Чөнки мәк - талымсыз чәчәк, аның орлыгы кайда төшсә, ул шунда үсәУкуытучы. Инде дәресебез башында куелган сорауга җавап табып карыйк: мәк чәчәгенең хәтер белән уртаклыгы нидә соң?

Укучы. Мәк чәчәген күпме генә утасаң да, ул һәрвакыт чыгып, үзе турында искәртеп тора. Кызыл чәчәкләре кан түсен символлаштыра. Сугыш турындагы Хәтер дә шулай, һәр яз саен яңадан яңара. Кан түсе - кызыл төс белән хәтерләребезне яңарта.

Укытучы. Әйе, укучылар, һәр яз саен Җиңү көнендә безнең тыныч тормышыбыз өчен башын салган миллионнарча каһарманнарыбызны искә алып, без җиңү парадлары, митинглар үткәрәбез. Аларны хәтерләребездә яңартабыз. Менә быел сугыш беткәнгә 70 ел тулачак. Инде безнең арабызда исән калган сугыш ветераннары да санаулы гына калып бара. Безнең авылдан ул - Кыям абый Җәләлов.

**Нәсерне йомгаклау.**

Укытучы. Нәсерне йомгаклап нәрсә әйтә алабыз? Бу нәсердә мәк нәрсә символыдыр дип уйлыйсыз? Җавапларыгызны дәлилләп тә үтү мөһим.

Укучылар. **(СИНГЛ РАУНД РОБИН структурасы буенча җавап бирә: команданың 4 кешесе дә чиратлап җавап бирә).**

- Шушы күпьеллык мәк чәчәге - елдан-елга шытып чыгучы хәтер символы. Чөнки ул:«Мин каннан һәм күлдән шытып чыктым",- ди.
- Мәк чәчәге татар әдәбиятында гына хәтер символы түгел, ә рус әдәбиятында да хәтер символы. Без моны Ю. Антоновның «Маки, маки, красные маки» җырының сүзләреннән дә күрәбез.
- Димәк, әлеге Җиңүне яулаган Солдат турындагы хәтер мәңгелек булырга тиеш.
- Тереклекне кытыршы куллары, мәрхәмәтле, киң йөрәге, батырлыгы белән саклап калган гади солдат-ны тереклекнең онытырга хакы юк.

Укучылар. Безнеңчә, мәк чәчәге биредә тереклек символын үти.

- «Мин тере. Әйе, мин ышанам, тормышның бетмәве, чәчәкләрнең кешеләрдән аерыл-мавы белән бәхетлемен…»- ди ул. Димәк, зур корбаннар хисабына сакланган, яңар-ган тереклекнең бәясе югары.
- Җирдә тереклектән дә зур кыйммәт юк.

Укытучы. Сез фикерләрегезне дәлилли алдыгыз һәм мине ышандырдыгыз. Бу фикерләрегезне берләштереп булмыймы?

Укучы. Була. Биредә мәк чәчәге- тереклекнең сугыш турындагы мәңгелек хәтере дип әйтә алабыз. Җирдәге тереклек фашизмны җиңгән сугыш героен мәңге онытмаска тиеш.

Укытучы. Әмма автор фикере кайда күренә соң?

Укучы. Ул гади Солдатка мәдхия җырлый дип әйтсәк тә була. Солдатның фашизмны җиңүен бөтен дөнья бәяләсен иде дия кебек. «Күл һәм каннан яралган чәчәкләрнең рәхмәте сезне мәңгелек дан һәм бәхеткә илтсен!»

**Дәресне йомгаклау.**

Укытучы. Укучылар, әсәрне анализлаганнан соң сездә нинди хисләр туды?

Укучы. **(ТАЙМД ПЭА ШЭА структурасы буенча укучылар янәшә парлар белән эшлиләр һәм җавап бирәләр.)**

-Хәтер безнең тормышта зур урын алып тора. Дөрес, кеше оныту белән бәхетле диләр. Әмма Бөек Ватан сугышы турындагы хәтерне безнең онытырга хакы-быз юк.

- Әлеге әсәр мине тетрәндерде. Әйе, Мәк чәчәге- ул җиңүне яулаган гади Солдат турындагы хәтер. Ә ул хәтер ел саен, хәтер уты кебек, мәк чәчәкләрендә кабына.

-Бу нәсерне карап чыкканнан соң, сугыш геройлары турындагы хәтернең дә мәк чәчәге кебек нәзберек тә, мәңгелек икәнен аңладым. Хәтер безгә үткәндәге хаталарны кабатламас өчен , яхшыларын арттырыр өчен кирәк.

-Кызганычка каршы, бүген дә дөньяның әле бер, әле икенче ноктасында сугыш утлары кабынып тора. Минемчә, бу кайбер илләрдә Бөек Җиңү турындагы хәтернең юкка чыгуыннан киләдер дип уйлыйм.

Укытучы. Безгә нишләргә соң?

Укучы. Ветераннарны хөрмәтләргә, обелискларны чистартырга, сугыш турында кинофильмнар карарга, әдәби әсәрләр укырга, һ.б. Ә иң мөһиме - фашизмны җиңгән гади Солдат турындагы хәтерне буыннан-буынга тапшырырга.

Укытучы. Бик дөрес әйтәсез. Укучылар, без сезнең белән музыка дәресендә мәк чәчәге турында җыр да өйрәнгән идек бит әле, әйдәгез, шуны бергәләп җырлап алыйк.


**"Мәк чәчәге" җырын башкаралар.**

Укытучы. Җиңү язын алып килгәннән соң бала казлар тезелешеп, җир шарын тагын ничә мәртәбә урадылар инде. Тагын , тагын урарлар, әмма каурыйларын гына сугыш ялкыны өтмәсен дә, сугыш сөреме тапламасын иде. Укучылар! Сез барыгыз да киләчәк кешеләре. Дөньяның нинди булыры сездән тора. Кешелекне фашизм коллыгыннан азат иткән сугыш батыры турындагы хәтерне буыннардан буынга тапшырыгыз!

**Өй эше бирү.**

Укытучы. Укучылар, бүгенге дәресебездә алган материалларга таянып, сез өегездә «Батырлыктан туган матурлык» дигән темага инша язып килерсез. Ә бүгенге дәрестә барыгыз да актив булганы өчен мин сезнең барыгызга да "5"ле билгесе куям. Дәрес бетте. Чыгарга мөмкин. Сау булыгыз!









# Балачагын сугыш урлаган

Әбиемнең хәтер-хатирәсен
Күңел түрләремдә йөртермен.
Сугыш кайтавазын еллар аша
Оныкларыма да илтермен.
Сугыш башланганда бигрәк нәни -
Алты яшьлек сабый булган ул.
Бу сугышның нинди зур кайгылар
Китерәсен ничек тойган ул.
Әтисенең ташлап китәчәген
Кызчык күңеле каян сизенгән?
Балачакның татлы мизгелләре
Шушы көннән мәңге өзелгән.
Башка балаларның әнисе бар,
Ул сеңлесе белән дөм ятим.
Әниләре күптән вафат булган,
Сабыйларны юатыр соң кем?
Ярый әле әби-бабай булган,
Аларга атап һәйкәл куярлык.
Барысына да исән калыр өчен
Ипи кирәк тамак туярлык.
Озын кышлар үтеп, җәйләр җитсә,
Бала күңеле шундый сөенә.
Яшел кычыткannar, кузгалаклар
Яше-карты ташый өенә.
Әби-бабай назы һәм җылысы
Баса алмый әтисен сагыну хисен.
"Тиздән кайтыр",- дигән өмет аны
Алдап йөртә һаман иртә-кичен.
Илгә килгән барлык авырлыкны
Күтәргән бар халык ил белән.
Кемнең ире исән, кемнең үлгән,
Авыр язмышларны кем белгән?
Сугыш бетте, инде берәм-берәм
Солдатлар да кайта башлаган.
Өзелеп көткән әти күренмәгән,
Хыяллары тагын алдаган.
Әтиләре әсирлектә булган,
Кара язмыш бүлгән юлларын.
Шул юллардан күзен ала алмый
Әби-бабай көткән улларын.
Күзләр җиткәч кенә кайта алган,
Өй эчләре тулган нур белән.
Күңелләрдә гөлләр чәчәк аткан,
Әйтерсең лә кабат яз килгән.
Бала сөенечен бүлешкәндәй,
Күзгә кояш хәтта елмая.
Назлы җилләр сыйпый чәчләреннән,
Шиңгән чәчкәләр дә уяна
Беркайчан да нәни балаларның
Күз яшьләре җиргә таммасын.
Илебездә сугыш фаҗигасе
Беркайчан да кабатланмасын!

*Фәйрүзә Кадыйрова, 10 сыйныф укучысы*



# ҖИҢҮ КӨНЕ ҖИҢЕЛ БИРЕЛМӘДЕ...

## Ул көннәрнең даны мәңгелек

Сугыш, сугыш... Кемнәрнең язмышына кагылмаган да, кемнәрнең башларына кайгы, күз яше, хәсрәт китермәгән ул. Бу сүз күп кенә кешеләр күңелендә аяныч һәм сагыш уята. Чөнки анда аларның әтиләре, абыйлары, ирләре һәлак булган. Әйе, Бөек Ватан сугышында күпме кеше һәлак булган, күпме кеше туган якларына гарипләнеп кайткан. Күп кенә балалар, аналар шушы сугыш аркасында якыннарын югалтканнар, ятим калганнар. Күпме яшь кызлар үзләренең сөйгән ярлары белән кавыша алмыйча, бәхетле тормыш корудан мәхрүм калганнар. Никадәр бала бер тапкыр да "Әти" сүзен әйтә алмый калган ...

...Бөек Ватан сугышының тынганына да җиде дистә ел вакыт үтеп китеп бара инде. Мин үзем дә, әти-әнием дә сугыш чорын күрмәдек. Без сугыш афәтен, аның бөтен фаҗигасен язучыларыбыз, шагыйрьләребез язган әсәрләр аша, әби-бабаларыбыз сөйләгәнне тыңлап кына күз алдына китерәбез. Сугыш дип әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә. Яшь-яшь егетләр, кызлар, туган җирләрен саклау өчен, фронтка китәләр. Безнең Шәтке авылыннан да илебезне немец илбасарларыннан азат итәргә дип, барлыгы 169 кеше сугышка киткән һәм 13 кеше хезмәт армиясендә катнашкан. Шушы 169 кеше арасыннан 13 кеше һәлак булган, ә 80 кеше исә хәбәрсез югалучылар исемлегенә керә. Җир җимертеп яшәргә хыяллanып йөргән 18 кешене бу көтелмәгән сугыш гарипләндереп, инвалид ясап кайтара. Бары тик 58 кеше генә сугыш тәмамлангач, җиңүчеләр булып, туган якларына әйләнеп кайталар.

Авылдан барлык сау-таза ир-егетләр сугышка чыгып киткәч, колхоз тылда калган 153 хатын-кызга һәм картлар, кул арасына керә башлаган яшүсмер балалар кулына кала. Сугыш кырында дошман белән күзгә-күз көрәшү зур батырлык булса, тылда юкны бар итеп яшәү һәм сугыштагы кешеләргә дә ярдәм күрсәтү, колхозны саклап калу мең газаплар белән башкарылган. Ләкин алар җиңү өчен дип, бөтен булган тырышлыкларын куялар. Үзләре ачтан үлсә дә, сугыш кырындагы ирләре, уллары ачтан интегә күрмәсен, тизрәк дошманны гына җиңеп кайтсын, дигән теләк белән соңгы ризыкларын да авызларыннан өзеп, сугышка җибәргәннәр. Тылда калганнарның лозунгысы бер булган: "Бөтенесе фронт өчен! Бөтенесе җиңү өчен!" Бу чорда эшче көчләр генә түгел, ә җанлы тарту көче булган атларның да рәтлерәкләрен сугышка алып китеп бетерү, ә монда калганнарының ашарга булмау аркасында күпләп үлүе сәбәпле, аларны үгезләр алыштыра. Әйе, "үгез җигеп җир эшкәрттек, симәнә ташыдык" дигән сүзләргә хәзер без сәерсенеп карыйбыз. Ләкин чынлыкта шулар белән эш барган шул. Боларны миңа шул вакыттагы авырлыкларны үз башыннан кичергән бабаем бик еш сөйли:

"... Сугыш башланганда миңа 12 яшь иде. Яңа гына башлангыч мәктәпнең 4 нче классын бетергән вакыт. Исәбем - күрше Нырсы авылына барып, укуымны 5 нче класста дәвам итү иде. Гаиләбездә 5 бала. Мин - иң олысы. Иң кечкенә сеңлем Минҗамалга 3 яшь.

"Сугыш" дигән сүзне мин инде бөтен нечкәлеге белән аңлый торган яшьтә идем. Ул башта, бик тиз тәмамланыр күк иде. Ләкин алай булып чыкмады шул. Минем укуга барырга дигән планым да үтәлми калды. Әти: " Укуга бара алмассың инде улым, өсбаш та кирәк, ашарга да әллә нәрсә юк бит,"- дип әйткәли башлады. Без көн саен аңа сугышка чакырып повестка килүен көтеп яши башладык. Аны бернича тапкыр военкоматка чакырсалар да, сугышка алмый, борып кайтаргаладылар. Аннары безнең авылны ниндидер йогышлы чир чыккан дип, карантинга яптылар. Авылдагы ирләрне сугышка алуны 1 елга кичектереп тордылар. Безнең авылга исән-имин сугыштан әйләнеп кайтучыларның күбрәк булуын менә шушы 1 еллык карантин аркасындадыр дип уйлыйм мин.

Әтине сугышка 1942 нче елның азагында алдылар. Шулай итеп, алтау өелеп калдык. Кечерәк яшьтә булганга, колхозда хезмәт көне эшләү миңа әле мәҗбүри түгел иде. Ләкин әнинең мине эшләтәсе килә. Эшләгәч, бер түләрләр әле, дигәч, мин, бригадирдан ялынып, эш сорап барганым хәтердә. Миңа ат белән басудан солы көлтәсе ташырга куштылар, ә язга чыккач, тырмага куйдылар. Ул вакытта чәчкечләр юк. Сукалаган җирдән тубалга ашлык салып кул белән чәчеп чыгалар. Ә менә аны күмдерер өчен агач тырмага ат җигеп, тырмалап чыгабыз. Мин иртәнге 3 тә торам. Башта ашарга барабыз. Фәйзулла бабай карчыгы үз өендә колхозга эшкә йөрүчеләр өчен аш пешереп куя. Суга арыш умачы (ул кап-кара була иде) болгата да, шул аш була инде. Аның тәмлелекләре! Шулай китәсең эшкә. Ә көндез ашарга - ярты литр сөт (булса), әллә нигә бер булса да 1 йомырка һәм 500 грамм ипи (колхозда эшләүчеләр өчен колхоз ипи салдырып, 500 гр. бирә иде). Ә кичкә - өйдә бәрәңге. Әни иртән бәрәңгене мичкә салып ашата, көндез - әрчеп, кич - боламык ясап. Ипи бөтенләй юк, аның урынына - бәрәңге ипие. "

Бабай, шулай итеп сөйли-сөйли, үзенең балачакта күргән авырлыкларын күз алдыннан үткәреп, беравык тын кала. Аннан ул табында өелеп кисеп куелган ипигә карап тора. Мөгаен, ул хәзерге муллык белән ул вакыттагы бер сынык икмәккә тилмергән вакытларын чагыштырып карагандыр. Әйе, хәзер безнең буын ризыкның кадерен бик белеп бетерми шул, чөнки без ачлыкны, авырлыкны күрмәгән. Ә менә безнең әби-бабаларыбыз аны күреп кенә түгел, ә үз башларыннан кичергән шул. Шуңа күрә алар бер валчык икмәкнең дә тәмен бик белеп, тәмләп ашыйлар.

Бабам, бераз уйланып торганнан соң, яңадан сүз башлый:

"Көз көне атлар әзәйгәч, колхоз үгезләр җигүгә күчте. Һәрбер хуҗалыктагы үгез бозауны суйдырмадылар. Хәстәрләп, колхозга тапшыралар. Колхоз яшьтән үзе үстерә. Кызыксындыру максатыннан, колхоз хуҗалыкка ипи бирә иде.

Әкренләп безнең елгылар да колхозның авыр эшләрен эшләүче кешеләргә әйләндек. Безне олы ирләр рәтенә кертеп, бригадаларга бүлә башладылар. Ат та җигә, печән дә чаба, сукалый да, печән дә өя - барысын да олы ирләр рәтендә эшләргә кирәк. Бик авыр була иде ул. Ләкин ничек тә эшне җиренә җиткереп эшләргә, үзебезне яхшы яктан күрсәтергә тырыша идек.

Үгез белән үзебезне дә "җигәләр". Өлкәннәр белән бертигез күреп хезмәт көне язалар. Ә түләгәндә бернәрсә дә юк. Ничәдер грамм - хезмәт көненә. Барлыгы 10-15 кг алдыкмы икән инде барлык хезмәт көненә ашлыкны..."

Бабам, шулай итеп, көн саен үзенең балачак хатирәләрен яңарта. Ә мин кызыксынып тыңлап утыра, аның сугышка киткән әтисе турында сорашам.

"... Әтиебез 1946 нчы елны исән-сау әйләнеп кайтты, аллага шөкер. Аны яшелчә бакчасына каравылчы итеп билгеләделәр. Колхоз бер тиен акча түләми. Сугыш еллары гына түгел, сугыштан соңгы еллар да бик авыр еллар булды шул, кызым. Әле мин 1954 нче елда армиядән кайтканда да ачлык хөкем сөрә иде авылда." Аның сөйләгәннәре буенча, аларның ул вакытта күргәннәре турында бер китап язарлык. "Ул вакытта без күргәннәрне сезгә Ходай күрсәтмәсен инде, беркайчан да, балам", - дип тәмамлый бабам сүзен. Бу сүзләрне әйткәндә аның күзләре яшьләнә. Ул безнең матур тормышта яшәвебезгә куанып, үзенең үткәндәге авыр балачагын онытасы килеп, шулай күңеле йомшарып китәдер дип уйлыйм мин.

Әйе, 1418 көн һәм төн дәвам иткән бу сугышта безнең илебезнең зур җиңүгә ирешүендә фронт батырлары гына түгел, ә тыл батырларының да өлеше бик зур, чөнки Ватанны азат итү бөтен халык эше булган һәм "Алар Ватанны сакладылар" дигәндә, без ул сугыш еллары халкын – барысын да күз алдында тотарга тиешбез: ул елларда яшәгән, сугышта катнашкан, тылда эшләгән кешеләрне. Шуңа күрә хөкүмәтебез дә күптәннән инде тыл батырларына да Бөек Ватан сугышында катнашучылар белән бертигез дәрәҗәдә игътибар күрсәтә башлады. Бу – бик сөенечле хәл, әлбәттә. Ләкин сугыш ветераннарының сафлары сирәгәйгән саен (алар хәзер безнең авылда берәү генә калды инде), тыл батырларының да саны кимү ягына таба бара. Ләкин безнең бәхетле тормышыбыз өчен үз-үзләрен корбан иткән авылдашларыбызның батырлыгын без беркайчан да онытмабыз һәм хөрмәт катыш соклану белән искә алырбыз.

Тиздән – Бөек Җиңү көне. Ул һәр елны дәһшәтле көннәрне искә төшерә, сугыш ветераннары күңелендә тарихи хатирәләрне яңарта. Чөнки 5 елга сузылган канкойгыч сугышның һәр көне йөрәкләрдә җуелмаслык эз калдырган. Без ел саен 9 нчы май көнендә мәктәбебез ишек алдында һәм авылыбыз уртасында куелган һәйкәлләргә тере чәчәк бәйләмнәре, веноклар куябыз, Бөек Җиңүгә багышланган бәйрәм тантанасында катнашабыз. Анда күкрәкләренә орден-медальләр таккан чал чәчле сугыш һәм тыл ветераннарын күргәч, безгә тыныч тормыш бүләк иткән өчен аларга карата рәхмәт хисе уяна. Чал чәчләреннән сыйпыйсы, дөньядагы иң матур сүзләр белән юатасы, мең рәхмәт әйтәсе килә аларга! Мәңгелек дан һәм мәңгелек хөрмәт Сезгә, хөрмәтле ветераннар!

Картаймагыз әле, ветераннар!
Сезгә тиеш әле бик күп язлар,
Сезгә тиеш әле бик күп назлар,
Картаймагыз әле, ветераннар!

Үземнең язмамны тәмамлап, бары тик шуны гына әйтәсем килә: сугышлар башка беркайчан да булмасын иде. Гөрләп туйлар узсын, сабыйлар тусын, барысы да әтиле-әниле тигез канат астында үссеннәр! Безнең әби-бабаларыбыз күргән ачы язмышны без төшләрдә дә күрмәсәк иде!

*Зөһрә Кадыйрова, 11 сыйныф укучысы*







### Балтачы егет



Борын-борын заманда яшәгән ди Әнвәр исемле бер ярлы егет. Аның бары тик бердәнбер иске ярык балтасы гына булган ди. Егетнең торыр өе дә булмаган. Ул патшада эшләгән һәм көненә өч кенә сум акча алган. Патша Әнвәрне үзенең ашаганнан калган калдык-постык ризыклары белән генә тукландырган. Шулай булса да, ул аңа бик авыр эшләр куша торган булган.

Көннәрдән беркөнне патша егетне урманга утынга дип җибәрә. Әнвәр ат җигеп, урманга китә. Шулай итеп, бара торгач, ул урманга килеп тә җитә. Аннары ул, җиң сызганып, бердәнбер шул ярык балтасы белән, шак та шок бәреп, агачны чаба башлый. Чаба торгач, бәхетсезлегенә каршы, балта нининдидер ташка бәреләдә, бөтенләй сынып ук чыга. Егет ни эшләргә дә белми, аптырап кала. Ул, сынган балтасына карап, елап җибәрә. “Ни эшләтә инде мине хәзер патша? Бердәнбер эш коралым да ватылды бит. Утынсыз кайтсам, патша миңа ни әйтер? Ул мине, мөгаен, куып чыгарыр инде. Мин кая барырмын? ” - дип уйлый егет, борчылып.

Ул шулай ни кылырга белми утырганда, аның янына бер куян килеп чыга. Озын колак моңаеп утырган егетнең каршысына килеп баса да болай ди:

- Әй, егет, зинһар өчен, үтермә мине. Менә ничә көн инде авызыма бернинди ризык капканым юк. Ачтан үләм бугай инде. Берәр нәрсә ашарга бирче?

Егет бер хәлсезләнгән куянга, бер үзенең көне буена дип бирелгән ике сынык ипиенә карап торды да, авыр сулап куйды. Ул үзенең әлеге соңгы ипиләрен бирсә, үзе ач калачак иде. Тик ул үз каршында, ипине күргәч, күзләре очкынланып киткән куянга карап торды да, ипи телемнәрен куянга тоттырды. Куян, ипине бик тәмләп, бер валчыгын да әрәм итмичә, якындагы агач төбенә утырып ашады да, егеткә бик зур рәхмәтләрен укыды.

- И, егеткәем, син мине үлемнән алып калдың. Бик зур рәхмәт сиңа! Инде мин синең өчен нәрсә эшли алам? Син нигә болай бик моңсуланып утырасың соң әле?

- И, куян дус, минем хәлләрем дә бик шәптән түгел шул. Бүген минем дә, мөгаен, бу якты дөньяда соңгы көнемдер.

- Туктале, син ни сөйлисең, нәрсә булды сиңа? Нинди кайгың бар? Сөйләп бирче миңа.

- Менә мин бүген үземнең бердәнбер эш коралым булган балтамны да сындырдым. Хәзер мин патшага утынны ничек итеп алып кайтыйм соң инде? Әгәр мин аның янына буш арба белән кайтсам, ул минем башымны кистерәчәк. Менә шуңа кайгырып утырам мин, куян дус.

Куян Әнвәрнең сүзен тыңлап бетергән дә бер читкә китеп уйланып торган. Шуннан соң ул егет каршына килеп баскан да болай дип сүз башлаган:

- Дустым, син бүген мине үлемнән алып калдың. Моның өчен мин дә сине үлемнән алып калырга тиеш. Менә сиңа мин тылсымлы балта бирәм. Коткарса, шушы балта гына коткара алачак сине. Бу балта сиңа бик күп уңышлар да китерер. Тик белеп тор: аны синнән башка беркем дә кулланырга тиеш түгел. Ул вакытта аның тылсымы бетәчәк, - дип ул егеткә бер матур гына, җыйнак кына балта тоттырды. Куян шулай дип әйтә дә юкка чыга.

Егет балтага сокланып карап торды да, куянга зур рәхмәтләрен укып, эшкә тотынды. Ул иске балтасы белән бер агачны аудару өчен никадәр азапланса, моның белән бер генә селтәнеп җибәрә - балта үзеннән-үзе эшли, агачлар да берсе артыннан берсе авып кына торалар. Егет балтаның үзе эшләвенә шаккаталар, куянга рәхмәтләрен кат-кат укый.

Шулай итеп бер олау утын да тиз генә әзерләнеп бетә. Егет, җырлый-җырлый, төялгән утыны өстенә утырып, авылга кайтып китә.

Шул көннән башлап, Әнвәр, барлык балта белән эшли торган эшләрне, күз ачып йомганчы, башкарып куя торган була. Бушаган вакытларында кешеләргә матур-матур тәрәзә йөзлекләре яки башка балта эшләре белән булыша торган була. Аның шулай тиз һәм оста итеп эшләвенә бар кеше дә гаҗәпләнә. Егетнең кулының осталыгын күреп, хәтта өйләр салырга да чакыра башлыйлар. Шулай итеп, егет якын-тирәдә танылып өлгерә. Ул үзенә берникадәр акча запасы туплагач, патша балта турында сизә күрмәсен тагын дип, аннан качып китәргә карар кыла һәм тиз арада үзнең планын тормышка да ашыра. Патша да аны алай бик эзләтеп маташмый, ярар, бер ач хәерче бетмәс әле эшкә, дип аның урынына башка бер кешене яллый.

Әнвәр исә, патшадан качып киткәч, читтә үзенә бик матур итеп йорт сала. Бер матур гына, акыллы гына кызны үзенә яр итеп сайлап, шул нигездә гомер кичерә башлый. Алар хатыны белән биш бала тәрбияләп үстерәләр. Ә Әнвәр үзе, гомере буе – картайганчы, балтасын кулыннан төшерми, тирә-якның атаклы балта остасына әверелә. Ул үзенең шушындый тормышы өчен гомере буе серле куянга рәхмәт укый. Тик аны теге урманда күпме генә очратырга тырышса да, башка беркайчан да күрә алмый. Үзенең тормышын хәл иткән ике сынык икмәкне дә ул мәңге исеннән чыгара алмады. Кая гына барса да, кесәсенә һәрчак бер-ике телем ипи тыгып чыга, шунда очраган җәнлекләргә, куяннарга бирeп китә. Ул шулай итеп, бәлки ачтан интеккәннәрe дә булыр, дип, аларны сыйлап китә торган була.

*Айсаф Мөхәммәтханов, 5 нче сыйныф укучысы*

### Баканың исеме каян килеп чыккан?

Борын-борын заманда яр буенда яшәгән, ди бер хайван. Ул коры җирдә сикергәләп йөргән, ә суга кергәч, рәхәтләнеп йөзгән, ди. Тамагы ачса, чебен-черкиләр белән тукланган, ди.



Шулай итеп, беркөнне аның туганнары ауга китә. Ә ул яр буенда үзе генә кала. Туганнары китеп озак та үтми, көчле җил чыгып, бик каты – чиләкләп яңгыр ява башлый. Елганың суы ярларыннан ташып чыгып, бөтен яр буена җәелгән. Җәелгән ташкын елга буенда уйнап йөргән әлеге хайванны да агызып китә башлый. Яңгыр ява башлагач, кире борылган туганнары кайтып җиткәндә, әлеге хайван шактый гына ара агып киткән була инде. Аны күреп, туганнары ярдәмгә ашыкканнар. Үзләре һаман:

- Коткарыгыз, бата! Коткарыгыз, бата! – дип кычкыралар икән.

Шул вакытта яр буеннан үтеп баручы ике малай бу хәлне күреп, агып киткән хайванны тиз генә коткарганнар. Ә үзләре бата сүзен ялгыш ишетеп, әлеге хайванга “бака” дигән исем биргәннәр. Иптәшләренә дә кайтып:

- Без бүген агып китеп баручы баканы коткардык, - дип сөйләп утырганнар.

Менә шул көннән башлап, әлеге җир-су хайванына бака дигән исем кушылып калган да инде.

### Тыңлаусыз дуңгыз

Борын-борын заманда, эти дә тумаганда, әни дә булмаганда, яшәгән, ди бер әтәч. Аның койрыгы булган, ди урак, кикриге булган, ди кәпәч. Ишегалдында ул булган, ди патша. Анда яшәүче барлык хайваннар, кош-кортлар аңа буйсынганнар, ди. Ул ятканда йокларга ятканнар, ә иртән ул аларны тагын көчле тавышы белән йокыларыннан уята торган булган.



Әтәч патшага ишегалдындагы хайваннар арасыннан бары тик бер генә хайван буйсынырга теләмәгән – ул да булса, дуңгыз. Ул гел үзе теләгән вакытта сазда ауный, ни эшлисе килсә шуны эшләп, кайчан ятасы килсә - шунда ятып, кайчан торасы килсә - шунда торып, әтәчкә исе китмичә, үзенчә тик йөри икән.

Әтәчнең мондый тыңлаусыз хайванга бик ачуы килә икән. Җитмәсә әле, дуңгыз, аны үчекләгәндәй, һаман мыркылдап та йөри икән бит.

Ул, көннәрдән бер көнне, ачуына түзалмыйча, аңа болай дип кычкырган:

- Син - тыңлаусыз хайван! Үзең һаман сазда ауныйсың. Без – мөселманнар чиста халык, синең итең безнең мөселман кешесенә хәрәм! Сине урыслар ашасын!

Шул көннән башлап, әтәчнең теләге кабул булган: чынлап та, дуңгыз итен безнең татар халкы чит ит итеп – хәрәм ризык буларак кабул итә һәм аны асрамый да башлый.

Шуның белән әкият тә беткән.

*Иделия Мингалиева, 6 нчы сыйныф укучысы*

### Кәлтә нигә оялган?



Борын заманда бер урманда кәлтә яшәгән, ди. Ул бик “шук куллы” булган, ди, ягъни бөтен хайваннарның да азыкларын урлап йөри торган була.

Беркөнне бу шулай – ияләнгән гадәт буенча, саесканның азыгын урлап яткан чагында, саескан моны күреп алган да:

- Син нишләп йөрисең минем өем тирәсендә? – дип тавыш чыгарган.

Кәлтә аптырап калмаган:

- Менә, саескан туташ, мин баканы кунакка чакырмакчы идем, син шуңа гына хәбәр итә алмассыңмы? – дигән.

- Ярар, бүген үк җиткерермен, - дигән сескан. Һәм ул бу хәбәрне бакага бик тиз генә җиткереп тә кайткан.

Бака бу хәбәргә бик сөенгән. Шул ук көнне кәлтәгә кунакка барырга әзерләнә дә башлаган. Үз чиратында, кәлтә дә кунак каршы алырга әзерләнергә тотынган. Ул, табынын әзерләп бетергәч, аның кырыена җиргә кара тамызган.

Менә матур итеп киенеп, кәс-кәс кенә басып, бака да килеп җиткән. Кәлтә кунагын бик ачык йөз белән каршы алган һәм аны табын янына чакырган. Шул вакытта бака табын янындагы карага китереп баскан. Аның тәпиләре пычранган. Ул моңа бик читенсенгән. Ә кәлтә бик борчылган кыяфәт чыгарып:

- И-и, анда кара түгелгән икән, Бака дус, гафу ит, тәпиләрең пычранды инде, бар тиз генә юып кил, - дип аны тәпиләрен юарга чыгарып җибәргән. Үзе шул арада тиз генә табындагы ризыкларны ашарга тотынган. Бака әйләнеп килгәндә, табында ризыклар хәйран кимегән була инде.

Менә бака тәпиләрен юып, яңадан табын янына килә. Шул вакыт кәлтә юри аның күлмәгенә сок түгеп җибәрә.

- Ай, бака җаным, ялгыш түгелеп китте, зинһар өчен гафу ит инде мин игътибарсызны,-диеп, баканы күлмәген алыштырырга чыгарып җибәрә. Үзе тагын тиз генә табында калган ризыкларны сыпыртырга керешә, икән.

Шулай итеп, бака икенче күлмәкләрен киеп, яңадан кунакка дип килсә, табында калдык-постык әйберләрдән башка бернәрсә дә калмаган була инде. Кәлтә кунакка чакырган булып, үзе кунагының ризыкларын да ашап бетергән була.

Баканың моңа бик нык ачуы килсә дә, ул аны кәлтәгә сиздерми.

- Ярый, кәлтә дус, сыйларың бик тәмле булды. Бик зур рәхмәт! Инде мин үзем сине кунакка көтеп калам, - дип, саубуллашып чыгып китә.

Кәлтә үзен кунакка чакырганга бик сөенә. Бәйрәмгә киеп барырга үзенең иң затлы киемнәрен барлый башлый.

Менә икенче көнне кәлтә, кәттә генә киенеп, бака дустына кунакка китә. Ә бака табынны су астында әзерләгән була. Ул кунакка кәлтәне генә түгел, башка хайваннарны да чакырган була.

Кәлтә табынның су астында булганын белгәч, бик нык борчыла, чөнки ул су астында озак тора алмый икән. Ләкин тәмле әйберләр ашыйсы килү теләге бик көчле була һәм ул бака артыннан суга сикерә. Тик шул арада кәлтә яңадан су өстенә калкып чыга икән. Ул шулай бер бата, бер калка торгач, тәмам арый. Аның инде ашыйсы килү теләге дә беткән була. Ә бака аның болай азапланганын күреп:

- Ничек, бака дус, сыем яхшы булдымы? – дип сорый. - Мин дә синдә кунакта бик яхшы "сыйланган" идем,- ди.

Башка хайваннар кәлтәдән кычкырып көлгәннәр. Кәлтә үзенең эше өчен бик үкенгән, оятыннан кая кереп китәр тишек тапмаган. Шул тирәдә генә ташлар яткан була һәм кәлтә шул ташлар арасына кереп югала.

Менә шул көннән башлап, кәлтәләр таш[illegible] ара-сын[illegible] к[illegible] күзенә чалын[illegible]ка [illegible] икән.

*Таңсылу Сонгатова, 6 н[illegible] сыйныф укучысы*

# Ял сәгатьләрендә

## Ребусларны чишсәгез, мәкальләрне укырсыз



Газетаны гамәлгә куючы: Шәтке урта мәктәбе администрациясе.

Безнең адрес: 422096. Шәтке авылы, Мәктәп урамы, 4. (тел. 53-119)

Мөхәррир: Сәвия Кадыйрова.
Редколлегия: Илсөяр Шәйхиева
Рәзифә Габделхаева,
Гөлфия Заляева

Компьютерда җыючы: Илсөяр Шәйхиева